**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

2019 елның 21 октябре **№ 15**

Кәкре Күл авыл җирлеге Башкарма комитетының
"Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ
регламентларын раслау турында"
26.12.2018 елның 14 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законны, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында; "Федераль мәгълүмат адреслы система турында» һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 26.07.2009 елның 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитетының "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 26.12.2018 елның 14 номерлы карарына теркәлгән 4 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**- 1.5 пунктның 3 абзацында:** "планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы "сүзләрен" урам-юл челтәре элементы һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда)".

**- 1.5 пунктның 5 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;"

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru ;Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында : http:pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам

Кәкре Күл авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: С.С. Елисеев